ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 08.10.2020 г. Казань № 376/2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләре, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган бертөр дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге турында», 2019 елның 18 сентябрендәге 2113-р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү

буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 8 октябрендәге № 376/2020 номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: милекчелек хокукында яки законлы башка нигездә электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына ия булган территориаль челтәр оешмалары һәм Татарстан Республикасы территориясендә җайга салына торган эшчәнлек башкара торган электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүче затлар (алга таба – җайга салынулы эшчәнлек башкара торган оешмалар).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Дәүләт комитеты урнашкан урын: Казан шәһәре, К. Маркс урамы, 66.

Дәүләт комитетының эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.00 башлап 16.45 кадәр, җомга 8.00 башлап 15.45 кадәр, төшке аш 12.00 башлап 12.45 кадәр; шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

Гаризалар кабул итү графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе – 8.00-16.45, җомга – 8.00-15.45.

Җәмәгать транспортында «Толстой» тукталышына кадәр килергә.

10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89, 91, 98 номерлы автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 номерлы троллейбуслар.

Керү – шәхесне таныклаучы документны күрсәтеп.

1.3.2. Дәүләт комитетының электр энергиясенә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 221-82-80, 221-82-50, 221-82-49.

Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – Дәүләт комитетының рәсми сайты) рәсми сайты адресы: http://kt.tatarstan.ru, Дәүләт комитетының электрон почта адресы: kt@tatar.ru.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен җаваплы булган Дәүләт комитеты структур бүлекчәсе хезмәткәренең электрон почта адресы: Nizamiev.Rustem@tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Дәүләт комитетының урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысуллар белән алынырга мөмкин:

1) Дәүләт комитетына телдән (шәхсән яки белешмә телефоны буенча) мөрәҗәгать иткәндә;

2) Дәүләт комитетына язма рәвештә, шул исәптән почта аша яисә «Татарстан Республикасы рәсми порталында интернет аша кабул итү» системасы аша электрон рәвештә (E-mail: kt@tatar.ru);

3) дәүләт хезмәте турында Дәүләт комитеты биналарында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары аша – мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү урыннарында.

Мәгълүмат стендларында һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турында белешмәләрне үз эченә ала;

4) Интернет челтәре аша:

Дәүләт комитетының рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында;

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәсендәге мәгълүмат стендларында бүлек белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.3.5. Дәүләт комитеты урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Дәүләт комитетының электрон почта адресы турында мәгълүмат Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында бүлек белгече тарафыннан урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Дәүләт комитеты җибәргән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон). Гаризаның тәкъдим ителгән формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

Идарә – Дәүләт комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү һәм бәяләрне (тарифлар) билгеләү турында карарлар һәм башка карарлар кабул итү өчен оештырылган Дәүләт комитетының коллегиаль органы;

эш буенча вәкаләтле зат – Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләргә сату өстәмәләрен билгеләү турындагы эшне карауны оештыру өчен билгеләнгән Дәүләт комитеты бүлеге хезмәткәре;

Татарстан Республикасында Ягулык-энергетика комплексы һәм торак-коммуналь хуҗалык оешмалары тарифларын фаразлау һәм анализлауның бердәм мәгълүмат-аналитика системасы (алга таба – Бердәм система) – җайга салынулы оешма белән Дәүләт комитеты арасында мәгълүматлар һәм электрон документлар белән конфиденциаль алмашуны тәэмин итә торган система;

«Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше системасы) – Татарстан Республикасында электрон документлар алмашу буенча, шулай ук Татарстан Республикасында электрон оештыру-боеру документларын булдыру, куллану, тапшыру һәм саклау өчен булдырылган дәүләт мәгълүмат системасы.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү | «Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары белән расланган Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую нигезләренең 3 пункты (алга таба – Нигезләр) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.1 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) билгеләү яисә бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту һәм тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтару турында карар | Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Бәяләр (тарифлар) һәм (яки) аларның чик дәрәҗәләрен билгеләү турындагы гаризаларны теркәү, карауга кабул итү һәм караудан баш тартуны күздә тоткан бәяләр (тарифлар) һәм (яки) аларның чик дәрәҗәләрен билгеләү регламентын һәм тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы карары формасын раслау турында» 2018 |

| | | |
|---|---|---|
| | | елның 19 июнендәге 837/18 номерлы боерыгы (алга таба – 834/18 номерлы регламент) |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган чираттагы хисап чоры башланачак чор алдыннан килгән елның 20 декабреннән соңга калмыйча.<br><br>Үзләренә карата элегрәк тарифлар дәүләт тарафыннан җайга салынмаган оешмалар өчен бәяләр (тарифлар) нигезли торган материаллар Дәүләт комитетына тулы күләмендә алынган датадан башлап 30 көн эчендә билгеләнә. Дәүләт комитеты карары буенча әлеге срок 30 көнгә озайтылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору законнарда каралмаган.<br>Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 7 эш көне эчендә Дәүләт комитеты карарның таныкланган күчермәсен, беркетмәне (беркетмәдән өземтәне) теркәп, әлеге карарда үзенә карата бәяләр (тарифлар) билгеләнгән җайга салынулы оешма адресына җибәрә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документларны теркәү датасыннан алып 14 эш көне эчендә җибәрелә. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары белән расланган Электр энергетикасында бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу (яңадан карау, куллану) кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 7 пункты<br><br>Кагыйдәләрнең 18 пункты;<br>834/18 номерлы регламентның 8 пункты<br><br>Кагыйдәләрнең 30 пункты;<br>834/18 номерлы регламентның 32 пункты<br>Кагыйдәләрнең 20 пункты;<br>834/18 номерлы регламентның 22 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм | Бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдим бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы гаризадан (1 нче кушымта) һәм | Кагыйдәләрнең 17 пункты;<br>834/18 номерлы регламентның 5 |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | кирәкле нигезләү материалларыннан тора.<br>Җайга салынулы бәяләр (тарифлар) һәм (яки) аларның чик дәрәҗәләрен билгеләү турында гаризага түбәндәге нигезләү материаллары теркәлә:<br>1) электр энергиясе балансы;<br>2) электр егәрлеге балансы, шул исәптән билгеләнгән, урнаштырылган, кулланылышта булган һәм эшләп торган генерацияләү куәте турында мәгълүмат;<br>3) җылылык энергиясенә карата ихтыяҗ һәм тәкъдимнәр балансы (катнаш эшләп чыгару режимында электр һәм җылылык энергиясен җитештерүне гамәлгә ашыручы электр энергетикасы субъектлары өчен);<br>4) җылылык егәрлеге балансы;<br>5) алдагы җайга салу чорында бухгалтерлык һәм статистика хисаплылыгы;<br>шәхси һәм производство ихтыяҗларына һәм челтәрләр буенча тапшыруга (югалтуларга) электр энергиясен тоту күләмен нигезләп, электр һәм җылылык энергиясен файдалану җибәрү исәпләмәсе (җылылык энергиясе өлешендә – катнаш эшләп чыгару режимында электр һәм җылылык энергиясе җитештерә торган электр энергетикасы субъектлары өчен);<br>7) бер урыннан икенче урынга алып баруны исәпкә алып, кулланыла торган ягулык структурасы һәм бәяләре турында белешмәләр;<br>8) Монополиягә каршы федераль хезмәт тарафыннан раслана торган методик күрсәтмәләр нигезендә эшләнгән икътисадый нигезләнгән беренчел белешмәләрне теркәп (кулланыла торган нормаларны һәм исәпләмә нормативларын күрсәтеп), җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыруга чыгымнар һәм кирәкле тулай табыш исәпләмәсе (шул исәптән электр челтәрләренә технологик ялгауга бәйле, алынмый калачак керемнәрне билгеләү буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт тарафыннан раслана торган методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә торган, чынлыкта алынмый калачак керемнәр исәпләмәсе);<br>9) электр һәм җылылык энергиясе базарларында күрсәтелә торган аерым хезмәтләргә бәяләр (тарифлар) исәпләмәсе; | пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 10) заем капиталын турыдан-туры финанслау һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле акчага ихтыяҗ булуын нигезләп, инвестиция программасы (инвестиция программасы проекты);<br>11) мондый программаларны эшләү Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, энергияне сак тоту программасының билгеләнгән таләпләре нигезендә эшләнгән программалары;<br>12) рәсми статистика һәм бухгалтерлык хисаплылыгы нигезендә яисә җайга салынулы эшчәнлек алып бара торган оешмаларның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган икътисадый нигезләнмәгән чыгымнарны (керемнәрне), тарифлар составында исәпкә алынмаган чыгымнарны, алдагы җайга салу чорында җайга салынулы оешмага бәйле булмаган сәбәпләр буенча алынмый калган керемне, шул исәптән алдагы җайга салучорында электр энергиясеннән килешүдән башка гына файдаланган затлар тарафыннан килешүдән башка гына кулланылган электр энергиясенең ачыкланган күләме бәясен түләттерү нәтиҗәсендә челтәр оешмасының барлыкка килгән өстәмә керемнәрен бәяләү;<br>13) җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыруны (фактта яки планлаштырыла торган) раслаучы документлар, – эшчәнлек алып бару өчен файдаланыла торган объектларга карата милек хокукын яки башка законлы нигезләрне раслый торган документлар һәм җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешүләр (юридик затны үзгәртеп корганда – тапшыру актлары);<br>14) кулланучының энергияне сак куллану һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, аның өчен исәпкә алу приборларын урнаштыру белән бәйле челтәр оешмасы чыгымнарын түләү бурычын раслаучы түбәндәге документларның берсе:<br>электр энергиясен исәпкә алу приборын урнаштыру шартларын җайга салучы, хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы һәм челтәр оешмасы арасында төзелгән килешү;<br>электр энергиясен исәпкә алу приборын урнаштыруга бәйле чыгымнарны мәҗбүри түләттерү турында законлы көченә кергән суд карары; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 15) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның һәм электр энергиясен тапшыру һәм (яки) технологик ялгау хезмәтләреннән файдаланучыларның мөрәҗәгатьләре өчен бүлеп бирелгән абонент номерының булуы турында мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган һәм мөрәҗәгать итүченең мөһере белән таныкланган белешмә (мөһер булган очракта);<br>16) трансформатор һәм башка подстанцияләрне, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү турында» 2015 елның 28 февралендәге 184 номерлы карары белән расланган электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәр оешмаларына кертү критерийларының 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән электр тапшыру линияләрен билгеләп, мөрәҗәгать итүченең электр челтәрен тоташтыруның мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан расланган һәм мөрәҗәгать итүченең мөһере (мөһер булган очракта) белән таныкланган схемалары;<br>17) гаризалар һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары белән расланган Электр энергиясе тапшыру хезмәтләреннән дискриминацияле булмаган нигездә файдалану һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләренең 6(1) пунктында күрсәтелгән нигезләү материаллары, алар электро энергиясен күчергәндә файдаланылган электр челтәрләре хуҗалыгы объектларында барлыкка килгән электр энергиясен технологик югалту күләмендәге электр энергиясен югалтуларны компенсацияләү максатларында электр энергиясе (егәрлек) сатып алу чыгымнарына компенсация алу нияте булган электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары милекчеләреннән яки башка законлы хуҗаларыннан территориаль челтәр оешмасына алынган очракта.<br>Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында гариза оешманың җитәкчесе яки ул вәкаләт биргән башка зат тарафыннан имзалана, җайга салынулы оешма мөһере (мөһер булган очракта) белән таныклана һәм бәяләр (тарифлар) билгеләү турында үзенә теркәлә торган нигезләү материаллары (төп нөсхәләр яки мөрәҗәгать итүче таныклаган күчермәләр) белән тапшырыла. | Кагыйдәләрнең 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза тегелми, номер беркетелми.<br>Гариза бланкы һәм нигезләү материаллары оешма белдергән таләпләрне расларга тиеш.<br>Документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүченең мөһере белән (булган очракта) таныкланырга һәм оешманың җаваплы затлары тарафыннан имзаланырга тиеш.<br>Документлар һәм нигезләү материаллары каты папкада туплана, папка, оешманың рәсми кыскартылган атамасын, җайга салынулы тариф төрен һәм җайга салу чорын күрсәтеп, басма хәрефләр белән, алгы һәм ян якларыннан имзаланырга тиеш.<br>Чыгымнарның һәр статьясын нигезләү аларны аныклаудан (ирекле формада исәп-хисап таблицасыннан) башланырга тиеш.<br>Документлар һәм нигезләү материаллары тарифларны җайга салу өлкәсендә законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.<br>Гариза һәм документлар бер нөсхәдә тапшырыла.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхси (оешманың вәкаләтле заты тарафыннан);<br>почта аша.<br>Оешмалар тарафыннан бер биттән артык булган кәгазьдә тапшырыла торган барлык нигезләү документлары номерланырга, тегелгән, соңгы битендә мөрәҗәгать итүченең мөһере (булган очракта) белән беркетелгән булырга һәм җитәкчесенең яисә аның вәкаләтле вәкиленең имзасы белән расланган булырга тиеш.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза бланкының электрон формасы һәм документларны тапшыру рәвешләре Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Җайга салынулы оешма, чираттагы җайга салу чорына кадәр, елның 1 маена кадәр, тарифларны җайга салу органына бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим кертә.<br>Җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар җайга салынулы органга чираттагы җайга салу чоры башланганчы 30 эш көненнән дә соңга калмыйча үз инициативасы буенча бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимнәргә өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны тапшыру тәртибе | Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында торган оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар каралмаган | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Эш ачудан баш тарту нигезләре:<br>җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар) күләме һәм җайга салуның озак сроклы параметрлары (инвестицияләнгән капиталның табышлылык ысулын яки кирәкле тулаем керемне озак сроклы индексацияләү ысулын кулланганда) күләме турында тәкъдимне бастырып чыгармау яисә бастырып чыгарылган әлеге тәкъдим җайга салу органына тапшырыла торган тәкъдимгә туры килми.<br>бәяләр (тарифлар) билгеләү турында гаризаны (агымдагы | |

| | | |
|---|---|---|
| | җайга салу чорына бәяләр (тарифлар) билгеләү очракларыннан тыш) җибәрү срокларын элек бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу башкарылмаган оешмалар өчен җибәрү. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт пошлинасы яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен башка түләү алынмый | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затны (мөрәҗәгать итүчене) кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон | Гариза тапшырылган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.<br>Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим тапшыру датасы:<br>а) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим турыдан-туры Дәүләт комитетына тапшырылган очракта – бәяләр (тарифлар) | |

| | | |
|---|---|---|
| формада | билгеләү турындагы гариза теркәлгән дата;<br>б) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим почта (курьер) элемтәсе белән җибәрелгән очракта – почта юлламасын элемтә оешмасына тапшыру турында почта юлламасында штемпель белән расланган дата;<br>в) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим электрон рәвештә тапшырган очракта – бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдим Дәүләт комитетының электрон документ әйләнеше системасында теркәлгән дата | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;<br>мәгълүмат стенды белән.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, Мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, мәгълүмат такталарында урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла: | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;<br>объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;<br>«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль законның 15 статьясының 7 пункты нигезендә, махсус өйрәтелгән булуынраслый торган документы булган очракта, озата йөрүче этне объектка кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.<br>2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, | |

| | | |
|---|---|---|
| | модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булмау;<br>4) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>Дәүләт комитеты бинасының җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында Дәүләт комитеты мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>гаризаны Интернет челтәрендә Дәүләт комитетының мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бииналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | порталында шәхси кабинет аша гариза тапшыру һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мондый мөмкинлек тудырылганнан соң).<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган гаризаны Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы).<br>Гаризаны электрон рәвештә бирү аны (һәм нигезләү документларын) кәгазьдә тапшыру мөмкинлеген чикләми.<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) аша электрон документ формасында гариза тапшыру мөмкинлеге гамәлгә ашырылганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу яки бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул итү;

4) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдимгә экспертиза;

5) бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул итү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау;

7) техник хатаны төзәтү.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм күрсәтү:

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача формада һәм (яисә) Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача формада һәм (яки) хат аша мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, мөрәҗәгать итүченең язмача һәм электрон почта аша килгән мөрәҗәгатеннән тыш, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүченең электрон почта аша килгән мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон почта аша мөрәҗәгать кергән көннән соң өч эш көне узганчы җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүченең язмача мөрәҗәгате буенча җавап мөрәҗәгать итүче адресына электрон документ әйләнеше системасы аша (мөрәҗәгать итүченең әлеге системага тоташтырылган очракта) яисә почта аша (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән системага тоташтырылмаган очракта) язма мөрәҗәгатьне теркәгән көннән 30 көн узганчы җавап җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү:

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, электрон документ әйләнеше системасы, Бердәм система, Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша Дәүләт комитетына гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә аңа документлар һәм материаллар

тапшыра.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза.

3.3.2. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече:

гаризаны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм, теркәлү номеры беркетеп һәм кабул итү көнен күрсәтеп, гаризаны электрон документ әйләнеше системасында терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү көне, ае, елы, беркетелгән кереш номеры турында тамга куеп, гариза күчермәсен тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.3.3. Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече гаризаны электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелгән гариза.

3.3.4. Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) гаризаны карый һәм тикшерү өчен электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү мәсьәләләрен алып баручы рәис урынбасарына (аның вазыйфаларын башкаручы затка) (алга таба – рәис урынбасары) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.3.5. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.3.6. Бүлек башлыгы гаризаны карый, җаваплы башкаручыны билгели һәм карау өчен аңа җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җаваплы башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.3.7. Җаваплы башкаручы документларның әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры килү-килмәве буенча һәм документларның дөрес рәсмиләштерелгән булу-булмавын: комплектлылыгын, күрсәтелгән кушымталары булуын, таныклый торган реквизитлары (имза, штамп, теркәлү номеры) булуын, гариза тутыруның төгәл булу-булмавын тикшерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән документлар.

3.4. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу яки тарифлар билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул итү:

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче законнарда билгеләнгән срокта әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны һәм материалларны тулы күләмендә тапшырган очракта, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар проектын әзерләү өчен җаваплы бүлек хезмәткәре (алга таба – җаваплы башкаручы), эш буенча вәкаләтле вәкилне күрсәтеп, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу, җайга салу методын сайлау, бүлек хезмәткәрләре арасыннан эш буенча вәкаләтле затны билгеләү турында боерык проекты әзерли һәм аны килештерү өчен бүлек башлыгына, юридик бүлек башлыгына, рәис урынбасарына җибәрә.

Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, рәис урынбасары бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын карый, килештерә. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын килештергәннән соң, рәис урынбасары тарафыннан әлеге документ килештерү өчен рәискә җиткерелә.

Рәис, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерык проектын карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерыкны терки.

Эш буенча вәкаләтле вәкил бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу хакында хат-белдерү проектын әзерли һәм аны килештерү өчен – бүлек башлыгына, имзалау өчен рәис урынбасарына юллый.

Бүлек башлыгы бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турында хат-белдерү проектын карый, килештерә.

Рәис урынбасары, бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турында хәбәр-белдерү проектын карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече хат-белдерүне терки һәм, кулга тапшыру турында белдереп, аны почта буенча мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачу турындагы боерык, мөрәҗәгать итүче адресына хат-белдерү.

3.4.2. Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, Дәүләт комитеты бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Җаваплы башкаручы бәяләр (тарифлар) билгеләүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм аны килештерү өчен бүлек башлыгына җибәрә.

Бүлек башлыгы хат-белдерүне карый, килештерә, аны рәис урынбасарына, юридик бүлеккә килештерү өчен җибәрә.

Юридик бүлек башлыгы бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында хат-белдерү проектын карый, килештерә.

Рәис урынбасары, хат-белдерүне карап, аны имзалау турында карар кабул итә.

Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече хат-белдерүне терки һәм аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура бәяләр (тарифлар) билгеләү турында гариза теркәлгәннән соң 14 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат-белдерү.

3.5. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тәкъдимгә экспертиза

Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачкан очракта, эш буенча вәкаләтле зат бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимгә бәяләрне (тарифны) исәпләгәндә исәпкә алынган чыгымнарның нигезле булу-булмавы, бәяләрне (тарифларны) исәпләү параметрларын билгеләүнең төгәл булу-булмавы өлешендә экспертиза уздыра, аның нәтиҗәләрен электр энергиясенә бәяләр (тарифлар) исәпләмәсе бәяләмәсендә (алга таба – бәяләмә) чагылдыра, анысы бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшкә теркәп куела.

Җайга салынулы оешмалар тарафыннан бәяләр (тарифлар) билгеләү турында тапшырылган тәкъдимне анализлау барышында бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы тәкъдимне тәгаенләштерү зарурлыгы барлыкка килсә, Дәүләт комитеты өстәмә белешмәләр соратып ала, шул исәптән җайга салынулы оешма тарафыннан алдагы җайга салу чорында фактта тотылган чыгымнарны раслый торганнарын да. Мондый мәгълүматларны тапшыру срогы Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә, әмма җайга салынулы оешмага рәсми мөрәҗәгать кергән көннән соң җиде эш көненнән дә ким булмаска тиеш. Өстәмә мәгълүматлар сорату зарурлыгы тарифларны җайга салу органы тарафыннан бәяләр (тарифлар) билгеләү турында эш ачудан баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып тормый.

Бәяләмә бүлек башлыгына һәм рәис урынбасарына килештерү өчен тапшырыла. Эксперт бәяләмәсен бүлек башлыгы һәм рәис урынбасары тарафыннан килештерү нәтиҗәләренә бәйле эш буенча вәкаләтле вәкил электр энергетика-сындагы тарифларны килештерү кәгазен (4 нче кушымта) төзи, ул, эксперт бәяләмәсен теркәп (мөрәҗәгать итүче соравы буенча) электрон почта аша килештерү өчен мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елга кадәрге елның 1 декабреннән соңга калмыйча;

үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шулай ук үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырыл-маган аерым оешмаларга электр энергетикасында җайга салынулы аерым эшчәнлек төрләренә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракта әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Дәүләт комитетына килгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт комитеты карары буенча әлеге вакыт 30 календарь көненә озайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: электр энергетикасында тарифларны килештерү кәгазе, бәяләмә.

3.6. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул итү:

3.6.1. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар проектын әзерләү өчен җаваплы бүлек хезмәткәре бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар проектын

әзерли, аны бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, рәис урынбасары белән килештерә һәм, алга таба Килештерү комиссиясе утырышында карау өчен, тариф карарларын кабул итүне оештыру, тикшереп тору һәм алып бару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тарифлар билгеләү турында әзерләнгән һәм тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлегенә җибәрелгән карар проекты.

3.6.2. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында килештерелгән карар проекты Дәүләт комитетының Килештерү комиссиясе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Килештерү комиссиясенең составын һәм эшчәнлек тәртибен раслау турында» 2018 елның 14 ноябрендәге 346 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә һәм срокларда карала.

Процедураның нәтиҗәсе: Дәүләт комитетының Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе һәм бәяләр (тарифлар) билгеләү турында Дәүләт комитеты идарәсе утырышына чыгарылган карар проекты.

3.6.3. Бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар Дәүләт комитеты идарәсе утырышында «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең эшчәнлек тәртибен һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында карау өчен мәсьәләләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2010 елның 26 августындагы 231 номерлы Дәүләт комитеты боерыгында каралган тәртиптә кабул ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләр (тарифлар) билгеләнә торган җайга салу чоры башланачак елның 20 декабреннән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган мөрәҗәгать итүчеләр өчен, шулай ук үзләренә карата элегрәк бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу гамәлгә ашырылмаган аерым оешмаларга электр энергетикасында җайга салынулы аерым эшчәнлек төрләренә бәяләр (тарифлар) билгеләнгән очракта әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза Дәүләт комитетына килгән көннән башлап 30 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт комитеты карары буенча әлеге вакыт 30 календарь көненә озайтылырга мөмкин.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар, Дәүләт комитеты идарәсе утырышы беркетмәсе.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.7.1. Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече Дәүләт комитеты идарәсе беркетмәсеннән өземтә һәм бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карарның расланган күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң биш календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә юлланган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, шул исәптән электрон почта ярдәмендә, яисә электрон документ әйләнеше системасы яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрелә.

3.8.1. Гомуми тәэмин итү һәм эшчәнлек бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.8.2. Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелгән техник хатаны төзәтү турындагы гариза.

3.8.3. Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

3.8.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.8.5. Бүлек башлыгы гаризаны карый һәм карау өчен бүлек хезмәткәренә җибәрә.

3.8.6. Бүлек хезмәткәре документларны карый һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле заттан гариза алынганнан соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (почта яки электрон адрес буенча җибәрелгән) җавап.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган заты һәм рәис урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм Мөрәҗәгать итүчеләрнең Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләү.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт комитеты актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт комитетының еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Тикшереп тору нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы федераль

**законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты яисә Дәүләт комитетының дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә рәис кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яисә Монополиягә каршы федераль хезмәткә тапшырыла.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп

иткәндә.

5.2. Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Дәүләт комитетының рәсми сайты, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган Дәүләт комитеты вазыйфаи затының, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.4. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә карала һәм Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6. Әлеге Регламентның 5.5 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, Мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, Дәүләт комитетында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен

гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта.

Оешманың фирма бланкында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

202... - .... елга электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә бәяләр (тарифлар) билгеләү (төзәтмәләр кертү) турында

## ГАРИЗА

Мөрәҗәгать итүче:______________________________________________________
(Оешманың тулы атамасы)

Оешма реквизитлары:______________________________________________________
(ИНН, КПП, ОКПО, ОКАТО, ОКОГУ)

________________________________________________________________________

Юридик адрес:___________________________________________________________

Почта адресы:___________________________________________________________

Оешма җитәкчесе:_______________________________________________________
(Ф.И.А.)

Башкаручы_____________________________________________________
(Ф.И.А.)

Элемтә өчен телефоннар, факс_____________________________________________

Электрон почта адресы_______________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең бәяләр (тарифлар) билгеләү өчен мөрәҗәгать итү нигезе:
_________________________________________________________________

Җайга салу чоры ________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең таләбе (тәкъдим ителә торган бәяләр (тарифлар) дәрәҗәсе), оешманың рәсми сайтында урнаштырып:

(НДС исәпкә алмыйча)

| Оешма атамасы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик чыгым (югалтулар) өчен түләү ставкасы | |
| | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| | 202.. | | | | | | |
| | … | | | | | | |
| | … | | | | | | |
| | … | | | | | | |
| | … | | | | | | |

Оешма җитәкчесе (яки ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле башка зат)
(тулы имза)

(оешма мөһере) Дата

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта.

# Килештерү кәгазе

Электр энергетикасында тарифлар

____________________________________

(оешманың атамасы)

(НДС исәпкә алмыйча)

<table>
<tr><td rowspan="9">Оешма атамасы</td><td rowspan="4">Ел</td><td colspan="3">1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр</td><td colspan="3">1 июльдән 31 декабрьгә кадәр</td></tr>
<tr><td colspan="2">Ике ставкалы тариф</td><td rowspan="2">Бер ставкалы тариф</td><td colspan="2">Ике ставкалы тариф</td><td rowspan="2">Бер ставкалы тариф</td></tr>
<tr><td>Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы</td><td>Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы</td><td>Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы</td><td>технологик чыгым өчен (югалтуларга) түләү ставкасы</td></tr>
<tr><td>сум/МВт·ай</td><td>сум/МВт·сәг</td><td>сум/кВт·сәг</td><td>сум/МВт·ай</td><td>сум/МВт·сәг</td><td>сум/кВт·сәг</td></tr>
<tr><td>202..</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>…</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>…</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>…</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>…</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Оешма җитәкчесе /______________/Фамилиясе, исеме, атасының исеме

имза

м. у.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә

____________________________________

Кемнән:__________________________

Техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза

__________________________________________________________ дәүләт хезмәте

(хезмәтнең аталышы)

күрсәтелгәндә җибәрелгән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яисә арифметик хата) турында хәбәр итәм

Язылган:____________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: _____________________________________________________

____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

e-mail:_________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

________________________________________ адресы буенча кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүегез турында үтенәм.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә(яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка

чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның ризалыгын раслыйм.

Раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча _____________ телефоны аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| _____________ | ________________ | (____________________) |
| (дата) | (имза) | (Фамилия, исем, ата исеме) |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) билгеләү, электр энергиясе белән гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары.

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адрес |
| --- | --- | --- |
| Рәис | (843) 221-82-18<br>(843) 221-82-01 | кt@tatar.ru |
| Рәиснең беренче урынбасары | (843) 221-82-05 | Aleksandr.Shtrom@tatar.ru |
| Электр энергиясенә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы | (843) 221-82-45 | Nizamiev.Rustem@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында бу юнәлеш буенча җаваплы вазыйфаи зат реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
| --- | --- | --- |
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе җитәкчесе | 8(843) 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru |